ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 21 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында” 2005 елның 29 декабрендәге 134-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, № 3; 2013, № 5; 2014, № 5, № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның җиденче абзацын үз көчен югалткан дип санарга;

2) 7 статьяда:
а) 3 өлештә:
беренче абзацта “Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару профессиональ хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару профессиональ формированиеләре” сүзләреннән соң “, тау-коткару эшләрен гамәлгә ашыручы һәлакәттән коткару профессиональ хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару профессиональ формированиеләреннән тыш,” сүзләрен өстәргә;
өченче абзацта “Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары каршындагы халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге бурычларны хәл итү буенча махсус вәкаләтле идарә органнары белән килештереп” сүзләрен “федераль башкарма хакимият органының халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге бурычларны хәл итү буенча махсус вәкаләтле территориаль органы белән килештереп, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге бурычларны хәл итү